

Үткән шимбәдә Кадошкино районындагы Большая Поляна (Иса) авылында яшәvчеләр Мордовия Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Артём Здунов белән очрашып сойләштеләр.
Авыл халкы беренче чиратта жирле эшкуар Игорь Рогожинга ярдәм сорап морәжәгать иттеләр. Игорь Рогожин авыл хужалыгы техникасы очен Кадошкинодан Большая Полянага, Насакан Потьмага, Глушково, Паево авылларына урман аша vтә торган юлны чистарткан, шул вакытта бульдозер белән 33 агач аударган. Эшмәкәргә карата УК РФ «Аеруча зур кvләмдә урман утыртмаларын законсыз кисv» (по статье 260 УК РФ «Незаконная рубка лесных насаждений, совершенная в особо крупном размере») маддәсе буенча жинаять эше кузгатылган.      Житәкчегә юлнын халык очен әһәмияте турында, дәлилләп, Румия Амин кызы Байбекова сойләп бирде.
- Халык, район житәкчелеге, Игорь белән сойләштем. Бу юл кешеләргә, чыннан да, кирәк; ул транспортнын район vзәгенә кадәр юлын сизелерлек киметә. МР Урман хужалыгы министрлыгына (Минсельхоз РМ) бу агачларнын урман фондына каравын билгеләv бурычын куйдым. Закон бозу булса - агачларны утыртырга кирәк. Бу хәлне жентекләп тикшерәчәкбез", – дип язган Instagramda  да Артём Здунов.
Тагы Большая Поляна авылы кешелә-ре житәкчегә салынган яна асфальт юл очен рәхмәтләрен белдерделәр, әмма анда юл знаклары һәм Октябрьская урамында сvvткәргеч кирәклеге, инвалид коляскасы vтәрлек оеннән юлга чыгарлык асфальт турында сvз барды. Мордовия Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Артём Здуновтан ничә дистә еллар коне-тоне авыл фельд-шеры булып хезмәт иткән Светлана Пет-ровна Тумпарованы хокvмәт билгесе белән бvләкләv момкинчелеге турында да халык ихластан соралды.